| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**06.09.2022** № **04-05-163**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу тәртибе турында

2004 нче елның 27 нче июлендә кабул ителгән “Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 нче маддәсенең 1 нче бүлегенең 3 нче пунктының “б” пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Боерыкка беркетелгән Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу Тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

2017 нче елның 20 нче июлендә чыгарылган “Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә, аны эшкә алучының вәкиле тарафыннан, Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында коммерциягә кагылышы булмаган оешмалар белән бер генә кеше идарә итүче башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү Тәртибе турында” 04-14/96 номерлы боерыгы;

2019 нчы елның 30 нчы апрелендә чыгарылган “Дәүләт комитеты рәисенең 2017 нче елның 20 нче июлендә язылган 04-14-96 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәренә аны эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында коммерциягә кагылышы булмаган оешмалар белән бер генә кеше идарә итүче башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” 04-0-05 / 41 номерлы боерыгы.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары И.Г. Багаутдиновка йөкләргә.

Рәис Р.Н. Сабиров

_06.09.2022_нче елгы **04-05-163**
номерлы
Татарстан Республикасының Сатып
алулар буенча дәүләт комитеты
боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алулары
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында (алга таба – граждан хезмәткәрләре, дәүләт комитеты) коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип эшкә алучының вәкиле булып Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе (аның вазифаларын башкаручы зат) (алга таба – рәис) булган граждан хезмәткәрләренә кагыла.

Әлеге Тәртип граждан хезмәткәрләренең сәяси партия, профессиональ союз органы, шул исәптән дәүләт комитетының башлангыч профсоюз оешмасының сайлап куелган органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек ияләре ширкәтенең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу очракларына кагылмый.

3. Граждан хезмәткәренең коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазифасына караган бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

4. Коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алу граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 номерлы кушымта нигезендә язма рәвештә гариза бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Граждан хезмәткәре гаризаны коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә катнаша башлаганчы дәүләт комитетының ришвәтчелекне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) тапшыра.

6. Җаваплы зат гаризаны алынган көнне әлеге Тәртипкә 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча Журналга теркәп куя.

Җаваплы зат гаризаның күчермәсен теркәлү турында тамга белән алынган көнне граждан хезмәткәренә, гаризаларны теркәү журналында имза куйдырып, кулына тапшыра яисә тапшыру турында белдерү белән почта аша җибәрә.

7. Җаваплы зат гаризаны карауны теркәлгән көннән биш эш көне эчендә гамәлгә ашыра һәм аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны карау барышында җаваплы зат гариза биргән граждан хезмәткәреннән, коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашу функцияләрен билгеләүче язма аңлатмалар һәм документлар соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт бирү яки бирмәү турында җөмлә булырга тиеш.

8. Җаваплы зат гаризаны бәяләмә һәм башка материаллар (булган очракта) белән граждан хезмәткәренә коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт бирү яки бирмәү турында Карар кабул итү өчен рәискә тапшыра.

Рәис җаваплы кешедән гариза алган көннән башлап ике эш көне эчендә карар кабул итә.

Карар гаризага тиешле резолюция өстәп рәсмиләштерелә.

9. Җаваплы зат рәис тарафыннан карар кабул ителгәннән соң ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа дәүләт комитеты мөһере белән расланган гаризаның рәис резолюциясе салынган күчермәсен имза куйдыртып тапшыра. Рәис резолюциясе салынган гаризаның оригиналы граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

Татарстан Республикасының дәүләт
граждан хезмәткәрләре тарафыннан
Татарстан Республикасының Сатып алулар
буенча дәүләт комитетында коммерциягә
кагылышы булмаган оешма белән идарә
итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен
рөхсәт алу Тәртибенә
1 номерлы Кушымта

Татарстан Республикасының Сатып
алулар буенча дәүләт комитеты
рәисенә

____________________________________

____________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, биләгән

____________________________________

вазифасы һәм структура бүлекчәсе, яшәгән

____________________________________

урынының адресы

____________________________________

телефон номеры)

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан
Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында
коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә
түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алуы турында
Гариза

______________________________________________________________________________

(бер генә кеше идарә итә торган башкарма органның яисә коллегиаль идарә органының исеме )

_________________________________________________________________ сыйфатында

______________________________________________________________________________

(оештыру-хокукый формасы,

______________________________________________________________________________

исеме, салым түләүченең идентификация номеры (ИНН), адрес)

белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт бирүегезне үтенәм.

| | | |
|---|---|---|
| _____________ | _______________ | _________________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Татарстан Республикасының дәүләт
граждан хезмәткәрләре тарафыннан
Татарстан Республикасының Сатып алулар
буенча дәүләт комитетында коммерциягә
кагылышы булмаган оешма белән идарә
итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен
рөхсәт алу Тәртибенә
2 номерлы Кушымта

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан
Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында
коммерциягә кагылышы булмаган оешма белән идарә итүдә
түләүсез нигездә катнашу өчен рөхсәт алуы турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| Бер-бер артлы № | Теркәү датасы | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Җаваплы кешенең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |